ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.04.2017 г.Мензелинск №318

«Минзәлә муниципаль районы муниципаль учреждениеләрендә хезмәт куючыларга түләү шартлары турында» Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының 2010 елның 24 августындагы №1135 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2010 елның 24 августындагы №678Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә

КАРАР ЧЫГАРАМ:

1. «Минзәлә муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 24.08.2010 ел, №1135 Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты карарына (Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының 24.09.2010 ел, № 1267, 27.12.2010 ел, № 1657, 13.01.20 11№8, Минзәлә муниципаль районы 16.09.2011 №879, 01.11.2011 № 1073, 07.03.2012 № 158, 18.06.2012 № 644.от 25.12.2012 № 1448, 28.12.2012 № 1467, 28.12.2012 № 1479, от 14.03.2013 № 235, от 14.03.2013 № 236, от 10.06.2013 № 549, от 02.08.2013 ел № 749, 30.12.2013 ел № 1443, 20.01.2014 № 62, 10.07.2014 № 604, 05.12.2014 № 1129, 11.03.2015 № 231, 26.03.2015 № 289, 14.07.2016 №775) түбәндәге үзгәрешләр:

Һөнәри хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә

күрсәтелгән карар белән расланган Минзәлә муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация төркемнәре: 2 бүлектә: 2.4 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«O_b=T_1 \text{ x } K_{mi}»;$$

җиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.5. Гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының, сәнгать-эстетик, күппрофильле һәм спорт юнәлешендәге өстәмә белем бирү оешмаларының, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен һөнәри-квалификация төркеме хезмәткәренең төп окладын түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_b=T_1 \text{ x } K_{mi} \text{ x } K_{mj} +P,$$

Kmj - тармакның өстенлеген арттыра торган коэффициенты;

P - китап басу продукциясе һәм вакытлы басмалар белән тәэмин итү өчен 100 сум күләмендә компенсация уку йөкләнешенә пропорциональ рәвештә билгеләнә, әмма төп эш урыны буенча бер ставкадан артмый.

Тармакның өстенлеген арттыручы коэффициент күләме педагогик хезмәткәрләрнең база окладын исәпләү өчен кулланыла һәм: мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында:

төп гомуми белеме булган хезмәткәрләр өчен урта гомуми белем һәм квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем бирү. - 1,000;

урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белемгә ия хезмәткәрләр өчен - 1,166;

югары белемле хезмәткәрләр өчен - бакалавриат - 1.223; югары белемле хезмәткәрләр өчен - специалитет яки магистратура, -1,166;

гомуми белем бирү оешмаларында:

беренче, икенче, өченче квалификация дәрәҗәсендәге педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме хезмәткәрләре өчен:

квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча төп гомуми белем, урта гомуми белем һәм урта һөнәри белем бирү - 1,000:

урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем - 1,200;

югары белем - бакалавриат, - 1,258; югары белем - специалитет яки магистратура - 1,200; дүртенче квалификация дәрәҗәсендәге педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме хезмәткәрләре өчен - 1,029; һөнәри белем бирү оешмаларында - 1,248; гамәлгә куючының норматив хокукый актлары белән һөнәри белем бирүнең тармак ресурс үзәкләре статусы бирелгән һөнәри белем бирү оешмаларында - 1,328;

сәнгать-эстетик, күппрофильле һәм спорт юнәлешендәге өстәмә белем бирү оешмаларында - 1,565;

ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен мәгариф оешмаларында - 1,362.»;

күрсәтелгән карар белән расланган Минзәлә муниципаль районының физик культура һәм спорт амуниципаль оешмалары хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә:

2 бүлекнең 2.4 пунктының җиденче абзацында «1,155» санын «1,565» саннарына алмаштырырга;

2. Әлеге карарның гамәлдә булу көче кагыла дип билгеләргә.
2017 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләре.

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль районының
Башкарма комитет җитәкчесе И.Т.Шагалиев